Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Урман–Кәләй авыл җирлегенең
Кәләй тимер юл станциясе поселогында гражданнар җыены нәтиҗәләре
турындагы карары

18ноябрь 2022 ел № 3

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2022елның 18ноябрендә09сәгать 00 минутта, 2022елның 18 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта,2022 елның 18 ноябрендә 11 сәгать 00 минутта, 2022 елның 18 ноябрендә 12 сәгать 00 минутта, 2022 елның 18 ноябрендә 17 сәгать 00 минутта узган гражданнарның этаплы җыен нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге "Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Урман–Кәләй авыл җирлегенең Кәләй тимер юл станциясе поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрүгә юнәлдерү белән килешәсезме: Кәләй тимер юл станциясе поселогында юлларны норматив хәлгә китерү, сметалар төзү, техник күзәтү үткәрү һәм җирлек милкенә рәсмиләштерү өчен түләү?" соравы буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде. Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 1507кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 847 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашучыларның 847«РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; катнашучыларның0«КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карарбирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Урман-Кәләй авыл җирлегенең Кәләй тимер юл станциясе поселогында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - чынбарлыкка туры килә.

2.«Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Урман–Кәләй авыл җирлегенең Кәләй тимер юл станциясе поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү,Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш (ата-аналарыннан, иреннән һәм балаларыннан) һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару:Кәләй тимер юл станциясе поселогында юлларны норматив хәлгә китерү, сметалар төзү, техник күзәтү үткәрү һәм җирлек милкенә рәсмиләштерү өчен түләүгә ризамы?" турындагы мәсьәлә буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга Кәләй тимер юл станциясе поселогы, Железнодорожная урамы, 38б йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Әлмәт муниципаль районы сайтында«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Урман-Кәләй авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Урман–Кәләй авыл җирлеге башлыгы Л.Н. Фәләхиев